Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Түбән Өскебаш авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

13.11. 2020 ел №17

«Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебаш авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 24 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Өскебаш авылы, Советская урамы, 66А нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 27 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Өскебаш авылы, Советская урамы, 66А нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә хәтле 4 һәм аннан артык бала булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Түбән Өскебаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Түбән Өскебаш авылы Советская урамына вак таш җәеп ремонт ясау; проект-смета документларын төзү , технадзор;

- Түбән Өскебаш авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;технадзор;

- видеокамералар алу (сатып алу) һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Түбән Өскебашта урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;

-Су башняларына койма тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;технадзор;

-янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую; янгын сүндерү машинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;технадзор;?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар жыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар жыенын оештыручы итеп. Түбән Өскебаш авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл жирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Өскебаш авыл жирлеге башлыгы: Н.М.Мөхәммәтжанов